| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.08.2023 ел Баулы шәһәре № 170

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының “Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында” 2018 елның 25 июнендәге 248 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 19 августындагы 989 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының “Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында” 2018 елның 26 июнендәге 248 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында нигезләмәгә (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 318 номерлы, 2020 елның 28 апрелендәге 90 номерлы, 2020 елның 25 маендагы 118 номерлы, 2021 елның 2 ноябрендәге 195 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 245 номерлы, 2022 елның 4 июлендәге 125 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 278 номерлы, 2023 елның 12 маендагы 118 номерлы кабул иткән карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

VIII бүлектә «Оешма җитәкчесенең, оешма җитәкчесе урынбасары, баш бухгалтеры хезмәт хакын билгеләү тәртибе»:

атаманы “балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе” сүзләре белән тулыландырырга;

10-12 пунктлары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«10. Балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенең вазифа хезмәт хакы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_{d_s} = O_{b_s} \times S,$$

кайда:

$O_{b_s}$ - балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенең төп хезмәт хакы 18 398 сум күләмендә билгеләнә;

S - эшләгән вакыты (ставкасы).

11. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр балалар иҗтимагый берләшмәләре ($B_{sr}$) белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr_s} = O_{d_s} \times D_{sr_s},$$

кайда:

$O_{d_s}$ - балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенең вазыйфаи хезмәт хакы күләме;

$D_{sr_s}$ - тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенең хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме 100 процентка тиң дип кабул ителә.

12. Компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексына ярашлы рәвештә, балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе өчен билгеләнә.».

2. Әлеге карар уз көченә 2023 елның 1 сентябрендә үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров